**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**

IV чакырылышның чираттан тыш утырышы

11 декабрь 2024 ел № 37 Урыссу штб

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының "Ютазы районында сәнәгать паркы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү турында"гы 24.12.2018 елның № 47 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру, предприятиеләргә һәм оешмаларга ярдәм итү, җитештерүне, сәнәгатьне үстерү, Ютазы муниципаль районы территориясендә эш урыннарын арттыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә капитал салулар рәвешендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция эшчәнлеге турында»гы 25.02.1999 елның № 39-ФЗ санлы Федераль законы, «Конкуренцияне яклау турында»гы 26.07.2006 елның 135-ФЗ санлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында"гы 25.1.1998 елның № 1872 санлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1999 елның 7 маендагы 284 санлы карары, шулай ук Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 29.07.2011 елның № 29 санлы карары белән расланган» Ютазы муниципаль районында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү тәртибе турында"гы нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Ютазы районында сәнәгать паркы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү турында»гы 24.12.2018 елның № 47 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта « 2022 елга» сүзләрен «2025 елга» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат

технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы –
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин